**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы**

# КАРАРЫ

2021 елның 30 апреле 49№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советының 2016 елның 19 апрелендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә чикләүләр билгеләнмәгән муниципаль һәм дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Җир кодексы, 2002 елның 24 июлендәге "Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрнең әйләнеше турында" 101-ФЗ номерлы Федераль закон, 2015 елның 26 декабрендәге "Татарстан Республикасында шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен яңадан бүлү турында" 108-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2015 елның 26 декабрендәге "Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 109-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2020 елның 30 декабрендәге «Территорияләрне комплекслы үстерүне тәэмин итү максатларында Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 494-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә чикләүләр билгеләнмәгән муниципаль һәм дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карар преамбуласында «Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2015 елның 12 гыйнварындагы «Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сатып алу хокукын торглар үткәрмичә генә раслый торган документлар исемлеген раслау турында» 1 нче номерлы боерыгы нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

7 бүлекнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә: "7) товар аквакультурасын (товар балыкчылыгын) гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән капиталь булмаган корылмалар, корылмалар төзү.";

7 бүлекнең 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә: "5) товар аквакультурасын (товар балыкчылыгын) гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән капиталь

булмаган корылмалар, корылмалар төзү максатларында балыкчылык кишәрлегеннән файдалану шартнамәсенең гамәлдә булу срогына.".

3 бүлектәге 3 пунктның 4 пунктчасында ", һәм территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру очраклары" сүзләрен төшереп калдырырга;

3 бүлекнең 14 пунктында ", 15 пунктта каралган очрактан тыш" сүзләрен төшереп калдырырга;

3 бүлектәге 15 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3 бүлектәге 21 пунктның 4 пунктчасында ", һәм территорияне комплексլы үзләштерү өчен җир кишәрлеген арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру очраклары" сүзләрен төшереп калдырырга;

4 бүлектәге 17 пунктының 2 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

3 бүлектәге 23 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4 бүлектәге 24 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4 бүлекнең 23 пунктында ",ә 24 пунктта каралган очракта, шулай ук территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә проекты" сүзләрен төшереп калдырырга;

25 пунктта ",ә 24 пунктта каралган очракта, шулай ук территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә" сүзләрен төшереп калдырырга;

26 пунктта ", ә 24 пунктта каралган очракта, шулай ук территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә проекты" сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми https://alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында бастырып чыгарырга һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район Башлыгы: А. Ф. Никошин